Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ

КАРАР

10.03.2025 Менделеевск ш. № 293

Менделеевск муниципаль районы Советының 2024 елның 16 июлендәге 261 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алынучы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында»21.01.2010 елның 21 гыйнварендагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге милкендәге арендалана торган күчемле һәм Күчемсез мөлкәткә һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында» 2024 елның 16 июлендәге 261 номерлы карарының 1 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

   «1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге арендалана торган мөлкәткә һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган мөлкәткә түләүне кичектереп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен 8 (сигез) ел һәм күчемле мөлкәт өчен 3 (өч) ел тәшкил итә дип билгеләргә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы советының финанс-бюджет мәсьәләләре буенча Даими комитетына йөкләргә.

Совет рәисе Р.И.Беляев